РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

13 февраль 2015 ел                                                                                № 4-45

**«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча муниципаль юридик бюро төзү турында»**

Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 декабрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 02 11 декабрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча муниципаль юридик бюро төзергә, Буа муниципаль районы башкарма комитеты белән бертигез башлангычларда.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча муниципаль юридик бюро турында нигезләмә Буа муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана дип билгеләргә.

3. «Байрак» («Ялав», «Байрак» ) газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе                                                  А.К. Айзетуллов